ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 737-93/тэ-2023

«Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән Түбән Кама шәһәрендәге куллanучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык чыганагы өчен 2024 – 2028 елларга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2023 №59-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Татэнерго» АҖ) Түбән Кама шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык чыганагы өчен календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 737-93/тэ-2023
карарына кушымта

# «Татэнерго» АЖ тарафыннан Түбән Кама шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык чыганагы өчен 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| 1 | Кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә тариф | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» АЖ | | | | |
| 1.1.1 | «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 23,22 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 33,57 | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 33,57 | - |
| | | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 34,98 | - |
| | | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 34,98 | - |
| | | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 36,38 | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 36,38 | - |
| | | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 37,83 | - |
| | | | 01.01.2028 башлап | 37,83 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 30.06.2028 кадәр | | |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 39,35 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге